СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш,
422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш.,
422190

тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ**
**№ 1-28**

**КАРАР**
**«20» январь, 2025 ел.**

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2018 елның 20 августындагы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» № 4-25 карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 1 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Муниципаль берәмлекнең кыскартылган исеме - "Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре".

2. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 45 пункт өстәргә:

«45) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.».

3. 30 статьяның 11, 12 өлешләрендә «(Татарстан Республикасы Премьер-министрының) " сүзләрен төшереп калдырырга;

4. 30 статьяның 16 пункты үз көчен югалтты дип танырга;

5. 40 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт өстәргә:

"10.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

6. 40 статьяның 5 өлешендә «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга;

7. 43 статьяның 5.1 өлешенең 12 пунктындагы «б» пунктчасында «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга;

8. 45 статьяның 5.8 өлешенең 12 пунктындагы «б» пунктчасында «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга;;

9. 46 статьяның 4 өлешендә «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга;

10. 49 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыра.»;.

11. В. 54 статьяның 3 өлешендә һәм 2 өлешенең 2 пунктында «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга;

12. 80 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасының яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасының электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар».

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре башлыгы
вазифаларын башкаручы

В.А.Захаров

SCAN AnyScanner